ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№398 от «14» 10 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 4 февралендәге “Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан товар җитештерүчеләргә, эш, хезмәт күрсәтүчеләргә - юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) индивидуаль эшкуарларга, физик затларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында“ 52 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш районы прокуратурасының 2025 елның 23 сентябрендәге №02-08-02-2025/Прдп249-25-20920021 протесты, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 4 февралендәге 52 нче номерлы карары ( 2025 елның 23 июлендәге 271 номерлы карарры редакцисендә) карар белән расланган Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан товар җитештерүчеләргә, эш, хезмәт күрсәтүчеләргә - юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) индивидуаль эшкуарларга, физик затларга субсидияләр бирү тәртибенә (алаг таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 тәртипнең 3.22 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.22. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Комиссия утырышы беркетмәсен комиссия секретаре алып бара, беркетмәгә комиссиянең утырышта булган барлык әгъзалары имза куя.

Комиссия үз эшчәнлегендә хәбәрдарлык принцибына таянып эш итә.

Комиссия түбәндәге карарларны кабул итәргә хокуклы:

1) әлеге Тәртипнең 3.8 пунктында күрсәтелгән документлар булмаган очракта оешмалар заявкаларын кире кагу турында;

2) җирле бюджет акчаларын бирү турында, бүлеп бирелә торган акчаларның күләме;

0000012953

3) җирле бюджет акчаларын бирүдән баш тарту турында.

4) әлеге Тәртиптә күрсәтелмәгән өстәмә (башка) документлар бирү кирәклеге турында.

Комиссия секретаре әлеге пунктта күрсәтелгән карарларның берсен кабул иткән көннән алып 5 эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә. Җирле бюджеттан акча бирү турында Карар кабул ителгән көннән алып 7 эш көне эчендә Комиссия секретаре тиешле карар проектын эшли.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://mamadysh.tatarstan.ru// веб адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.В. Потеряхинага йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.М.Никифоров